**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«05» 10 2022 ел Яр Чаллы ш. № 2954

2022-2023 уку елында Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү чаралары планын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турында нигезләмәне раслау хакында» 1999 елның 31 декабрендәге 1441 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын үтәү йөзеннән һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүне камилләштерү максатында,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

- 2022-2023 уку елында ТР Тукай муниципаль районында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча төп чаралар планын 1 кушымта нигезендә;
- Тукай муниципаль районының мәгариф оешмаларын тикшерү буенча комиссия составын 2 кушымта нигезендә;
- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының мәгариф оешмаларын тикшерү буенча кабатлаучы комиссия составын 3 кушымта нигезендә.

2. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлегенә, Тукай муниципаль районы территориясендә урнашкан предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләренә, Тукай муниципаль районы территориясендә эшчәнлекләре рөхсәт ителгән иҗтимагый берләшмәләргә кирәкле чаралар күрергә тәкъдим итәргә:

– призыв яшенә кадәрге яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләү;
– мәгариф оешмаларында, укыту пунктларында, шулай ук хәрби-патриотик, яшьләр һәм балалар берләшмәләрендә гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләү эшен оештыру;
– мәгариф оешмаларының, укыту пунктларының, спорт комплексларының һәм гражданнарны патриотик тәрбияләү һәм призывка кадәр әзерләү үзәкләренең булган укыту-матди базасын камилләштерү;
– гамәлдәге спорт-гамәли һәм хәрби-техник секцияләрнең һәм клубларның эшләп торуы;

– призыв яшенә кадәрге гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләү буенча эшне оештырганда, мәгариф оешмаларының, оешмаларның һәм муниципаль берәмлекләрнең спорт инфраструктурасын актив файдалану буенча.

3. «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге белән берлектә эшне дәвам итәргә тәкъдим итәргә:

– белем бирү учреждениеләрен һәм укыту пунктларын педагогик кадрлар белән тәэмин итү;

– Татарстан Республикасында яшь армия хәрәкәтен үстерү буенча.

4. «Тукай районы үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә профилактик медицина тикшерүләре нәтиҗәләре буенча, беренчел хәрби исәпкә куелганнан соң һәм хәрби хезмәткә чакыру нәтиҗәләре буенча ярдәмгә мохтаҗ яшь егетләр белән дәвалау-савыктыру чараларын уздыруның үз вакытында һәм тулы булуын тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлегенә, «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, Татарстан Республикасы Тукай районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты белән берлектә, гражданнарга патриотик тәрбия бирү, хәрби хезмәт узу белән кызыксынуны арттыру, хәрби хезмәткә чакырылучыларны социаль яклау буенча даими рәвештә мәдәни-массакүләм чаралар үткәрергә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА * РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ * ИНН 1639031830 Р 06-88/09

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның «05» 10 2954 номерлы карарына 1 кушымта

2022-2023 уку елында ТР Тукай муниципаль районында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча төп чаралар планы

| № | Чараң исеме | Җаваплы башкаручы | Үткәрү срогы |
|---|---|---|---|
| **I. Оештыру чаралары** | | | |
| 1. | Төп планлаштыручы документларны эшләү, шул исәптән:<br>а) 2022/2023 уку елында Татарстан Республикасында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү турында карар проектын;<br>б) 2022/2023 уку елында хәрби хезмәт нигезләре буенча уку җыеннарын оештыру һәм үткәрү турында күрсәтмә проектын. | «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ | уку елы дәвамында |
| 2. | Хәрби частьләре һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында шефлык элемтәләрен киңәйтү буенча эш алып бару. | «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | уку елы дәвамында |
| **II. Хәрби хезмәткә әзерлекне кадрлар белән һәм укыту-методик тәэмин итү** | | | |
| 1. | Тукай муниципаль районы мәгариф оешмаларын тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләрен укытучы-оештыручылар белән комплектлау. | «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты. | даими |
| 2. | Белем бирү оешмаларына «Тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләре», «Тормыш эшчәнлеге иминлеге» курсларын укыту өчен укыту-методик һәм күрсәтмә әсбаплар белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү. | ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты. | даими |
| **III. Гражданнарны хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерләү** | | | |
| 1. | Гражданнарны хәрби хезмәт нигезләре буенча | «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф | уку елы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | укытуны оештыру. | идарәсе» МКУ, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | дәвамында |
| 2. | Гомуми белем бирү оешмаларының 10 сыйныф укучылары белән хәрби хезмәт нигезләре буенча уку җыеннары үткәрү. | «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | уку елы дәвамында |
| 3. | Хәрби хезмәт нигезләре буенча конкурслар, ярышлар, олимпиадалар үткәрү. | ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге, ТР ДОСААФы. | уку елы дәвамында |
| | **IV. Гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләү** | | |
| 1. | Мәгариф оешмаларында Батырлык дәресләре, Ватан тарихына багышланган сыйныфтан тыш чаралар уздыру. | ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге, ТР ДОСААФы. | уку елы дәвамында |
| 2. | Мәгариф оешмаларында музейлар һәм сугышчан дан почмакларының Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган смотр-конкурсын уздыру. | ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге, ТР ДОСААФы. | уку елы дәвамында |
| 3. | Ватанны саклаучылар көненә һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган оборона-массакүләм һәм спорт эшләре буенча чаралар үткәрү. | ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге, ТР ДОСААФы. | уку елы дәвамында |
| 4. | «Хәрби хезмәткә чакырылучылар көне» социаль-патриотик акциясен уздыру. | «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | 2022 елның 25 ноябренә кадәр 2022 елның 25 маена кадәр |
| 5. | РФ Кораллы Көчләренә чакырылырга тиешле гражданнар арасында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган хәрби-гамәли һәм спорт-техник спорт төрләре буенча ярышлар уздыру. | ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге, ТР ДОСААФы. | уку елы дәвамында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Балалар һәм яшьләр өчен Яр Чаллы шәһәренең хәрби комиссариатлары вәкилләре, шулай ук Бөек Ватан сугышы, Әфганстандагы сугыш, Төньяк Кавказдагы контртеррористик операция ветераннары белән очрашуларын һәм сугышчан дан көннәрен үткәрү. | ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге, ТР ДОСААФы. | уку елы дәвамында |
| 7. | Хәрби-патриотик яшүсмерләр клубларының һәм «ЮНАРМИЯ» Бөтенроссия балалар-яшүсмерләр хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәте отрядларының шәһәр слетын үткәрү. | «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, Тукай районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | уку елы дәвамында |
| **V. Медицина таныклавы һәм медицина тикшерүе** | | | |
| 1. | Гражданнарны медицина таныклавында катнашучы табиб белгечләр белән инструкторлык-методик җыен үткәрү. | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | 2022 елның 25 сентябреннән 2023 елның 25 маеннан |
| 2. | Беренчел хәрби исәпкә куелганда гражданнарга медицина таныклавын һәм тикшерүен оештыру һәм уздыру. | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | 2023 елның 31 мартына кадәр |
| 3. | Гражданнарны беренчел хәрби исәпкә куюдан алып, аларны хәрби хезмәткә чакырганчыга кадәр чор эчендә гражданнарга медицина тикшерүен, аның үз вакытында тәмамлауныуын контрольдә тотып, гамәлгә ашыру | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | 2022 елның 30 декабренә кадәр 2023 елның 30 декабренә кадәр |
| **VI. Дәвалау-сәламәтләндерү эше** | | | |
| 1. | Беренчел хәрби исәпкә кую нәтиҗәләре буенча 1-3 номерлы исемлекләргә кертелгән, шулай ук хәрби хезмәткә чакыру нәтиҗәләре буенча вакытлыча яраксыз дип табылган 2006 елгы гражданнар белән дәвалау-сәламәтләндерү чараларын уздыру. | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | уку елы дәвамында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | 15-16 яшьлек яшүсмерләргә (2006-2007) беренчел хәрби исәпкә куелганчы профилактик медицина тикшерүләре үткәрү. | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 31.03.2022-31.05.2023 |
| 3. | Хәрби хезмәткә чакырылганга кадәр гражданнар белән дәвалау-савыктыру чараларын уздыру нәтиҗәлелегенә контроль. | «Тукай районы үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | 2022 елның 30 декабренә, 2023 елның 29 июленә кадәр |
| 4. | Көндезге уку формасында югары белем бирү оешмаларында укучы һәм укуын тәмамлаган укучыларны тикшерү үткәрү барышына контроль. | «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | 2022 елның 30 декабренә, 2023 елның 14 июленә кадәр |
| **VII. Хәрби хезмәткә гражданнарның ирекле әзерлеге** | | | |
| 1. | Россия Федерациясе Оборона министрлыгының хәрби һөнәри белем бирү оешмаларына керү өчен кандидатларны сайлап алуны оештыру һәм җибәрү. | «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | 01.02.-28.04.2023 |
| 2. | Суворов хәрби училищеларына, хәрби-музыка училищеларына, кадет корпусларына, Нахимов хәрби-диңгез училищесына керү өчен кандидатлар туплау һәм аларны җибәрү. | «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | 01.02.-24.07.2023 |
| 3. | Спортның хәрби-гамәли төрләре буенча клублар, секцияләр, түгәрәкләр эшен оештыру һәм аларның слетларын үткәрү. | Тукай районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, ТР ДОСААФы. | уку елы дәвамында |
| 4. | Тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләрен укытучылар-оештыручылар вазыйфасына югары белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан запастагы офицерларны сайлап алуны оештыру. | «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, ТР Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча бүлеге. | уку елы дәвамында |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның «05» 10 номерлы 2954 карарына 2 кушымта

**Тукай муниципаль районының мәгариф оешмаларын тикшерү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| **Комиссия рәисе:** | |
| Вәлиев Д.Ш. | Бүлек (Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы буенча) башлыгы |
| **Комиссия әгъзалары:** | |
| Сабиров Ә.З. | «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы |
| Гәрәев И.Р. | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы |
| Рыбакова Ю.М. | Мәдәният бүлеге башлыгы |
| Кузина Л.В. | Бүлекчә (гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү һәм чакыру) башлыгының өлкән ярдәмчесе |
| Габделхакова Д.Р. | Бүлекчә (мобилизацион ресурсларны планлаштыру, билгеләү, әзерләү һәм исәпкә алу) башлыгы ярдәмчесе |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның «05» 10 2984 номерлы карарына 3 кушымта

**Тукай муниципаль районының мәгариф оешмаларын тикшерү буенча кабатлаучы комиссия составы**

**Комиссия рәисе:**

| | |
|---|---|
| Минһаҗев Б.Г. | Бүлекчә (гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү һәм чакыру) башлыгы |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Хәбетдинова Г.Ф. | «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгының укыту эшләре буенча урынбасары |
| Вәзиева А.Д. | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге баш белгече |
| Ряднинский С.М. | Бүлекчә (мобилизацион ресурсларны планлаштыру, билгеләү, әзерләү һәм исәпкә алу) башлыгы ярдәмчесе |
| Бадамшина Р.И. | Бүлекчә (мобилизацион ресурсларны планлаштыру, билгеләү, әзерләү һәм исәпкә алу) башлыгы ярдәмчесе |